1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясенә, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 06 май
№ ПУ-259

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның «06» маендагы
ПУ-259 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе (алга таба – Концепция) сәяси-хокукый карашларның, рухи юнәлешләрнең, принциплар һәм өстенлекләрнең системага салынган җыелмасыннан гыйбарәт, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының (алга таба – дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары) эшчәнлеген, аларның этник үсеш һәм милләтара (этносара) мөнәсәбәтләр өлкәсендә граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген координацияләү өчен нигез булып тора.

2. Концепция буенча Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте объекты булып Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милләтара (этносара) мөнәсәбәтләре һәм аларның этномәдәни үсеш даирәсе тора.

3. Концепция – Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең өстенлекләрен, максатларын, принципларын, бурычларын, төп юнәлешләрен, шулай ук аны тормышка ашыру алымнарын һәм механизмнарын билгеләүче документ.

4. Концепция дәүләт, җәмгыять, кеше һәм граждан мәнфәгатьләрен тәэмин итү, Россия Федерациясенең дәүләти бердәмлеген һәм бөтенлеген ныгыту, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни үзенчәлеген саклап калу, гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү, дәүләт һәм җәмгыять мәнфәгатьләрен җайга салу максатларында эшләнде.

5. Концепциянең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, федераль һәм республика законнары, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы шартнамәләр (килешүләр) тәшкил итә.

6. Концепция Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең тарихи гореф-гадәтләрен, табигать, климат шартларын һәм табигый-икътисадый шартларны, алар тормышының социаль-мәдәни үзенчәлекләрен, геосәяси һәм милли мохитне, аларның күршеләре белән үзара мөнәсәбәтләре тәҗрибәсен аңлауга нигезләнә, анда Татарстан Республикасындагы хәзерге этносоциаль вазгыять чагылыш таба.

7. Концепция дәүләт (милли) иминлеген тәэмин итү, озак вакытка исәпләнгән социаль-икътисадый үсеш, төбәк, миграция, тел һәм яшьләр сәясәте, мәгариф һәм мәдәният өлкәләрендә дәүләтнең стратегик планлаштыру документларын, Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсенә кагылышлы башка документларны, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән (Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 6 декабрендәге 703 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясенең төп нигезләмәләрен исәпкә алып эшләнде.

8. Әлеге Концепция гомуми социаль, сәяси һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итүгә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының нәтиҗәле үзара хезмәттәшлегенә, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милләтара татулык һәм тынычлык, диннәргә тигез караш, бер-берсен этник мәдәни кыйммәтләр белән баету традицияләрен үстерүгә, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын тәэмин итүгә, дәүләт милли сәясәте өлкәсенә кагылышлы максатчан проектлар һәм программалар эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән.

9. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең аеруча игътибар бирелергә тиешле мәсьәләләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) Татарстан Республикасы халкында гражданлык бердәмлеген, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык үзаңын) һәм аның контекстында формалашучы Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту;

б) Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең мәдәният һәм тел ягыннан төрлелеген саклап калу һәм үстерү, аларның рухи бердәмлеген ныгыту;

в) Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтләр арасында аралашу теле буларак рус телен саклап калу;

г) Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү;

д) милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә каршылыкларны бетерү, экстремистлыкны профилактикалау, милли һәм дини җирлектәге низагларны кисәтү, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның яңа шартларга җайлашуы өчен мөмкинлекләр тудыру;

е) Татарстан Республикасын татар халкының рухи һәм этномәдәни мәркәзе дип тану, Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларның интеллектуаль, икътисадый һәм этномәдәни берләшүе өчен шартлар булдыру;

ж) чит илләрдә яшәүче ватандашларга булышлык күрсәтү, аларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы белән элемтәләрен үстерүгә һәм ирекле рәвештә Россия Федерациясенә күчеп кайтуына ярдәм итү.

10. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыру гомумроссия граждан тәңгәллеген һәм Татарстан граждан тәңгәллеген ныгытуга ярдәм итүче туплау факторы булырга тиеш.

11. Әлеге Концепция дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте мәсьәләләрен хәл итүнең бердәм алымнарын эшләүгә булышлык итәргә тиеш.

12. Әлеге Концепция комплекслы тармакара социаль юнәлешле була һәм Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы (Россия милләте) мөмкинлекләрен үстерүгә хезмәт итә.

## II. Татарстан Республикасында милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең хәзерге торышы

13. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте ике фундаменталь өстенлекле нигезләмәгә: Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең тормыш-яшәеше өчен тигез шартлар тәэмин итү һәм татар халкын һәрьяклап үстерү һәм Татарстан Республикасын аның дәүләтчелегенең тарихи формасы буларак ныгыту зарурлыгына таянып корыла.

14. Татарстан халкының күпэтнослы һәм күпконфессияле булуы – республиканың үзенчәлеге, аның үсеше тыгыз этномәдәни йогынтылар һәм хәзерге Татарстан территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре традицияләренең үзара катнашуы белән сыйфатлана. Әлеге процесста Татарстан Республикасында яшәүче барлык башка халыклар вәкилләренә карата күпчелекне тәшкил иткән татар һәм рус халкы вәкилләре традицион рәвештә әйдәүче рольне уйнады һәм уйный. 2010 елдагы халык санын алу йомгаклары буенча Татарстан Республикасында 3,78 миллион кешенең 53,2 процентын – татарлар, 39,7 процентын руслар тәшкил итә. Идел буе халыклары вәкилләреннән Татарстан территориясендә чувашлар, удмуртлар, мордвалар, марилар һәм башкортлар яши, тулаем алганда, алар Татарстан халкының 5,6 процентын тәшкил итә.

15. Хәзерге Татарстан территориясендә җирле җәмгыятьнең милләтара (этносара) һәм конфессияара уңай мөнәсәбәтләр урнашкан тарихи аерым бер төре оешты. Гасырлар буе бергәләшеп яшәү дәвамында күркәм күршелек, төрле диннәргә тигез караш, милләтара (этносара) татулык һәм хезмәттәшлекнең тотрыклы сыйфатлары формалашты. Традицияләргә таяну

тискәре милли-радикаль сәяси тенденцияләр йогынтысын нейтральләштерергә, республикада милләтара һәм динара тынычлыкны һәм үзара аңлашуны саклап калып, экстремизм чагылышларына каршы торырга мөмкинлек бирә.

16. Тарих барышында төрле төркиләрне һәм фин-угорларны үзенә катнаштырган, соңрак славян йогынтысын да кичергән татар халкының мең елдан артып киткән дәүләтчелек тарихы бар. Аның турындагы күзаллаулар татар халкы менталитетының аерылгысыз өлешен тәшкил итә, милли-дини үзаңы үсешенә этәргеч бирә, күп вакытта татарларның башка халыклар белән үзара мөнәсәбәтләре эчтәлеген һәм характерын билгели. Шуның белән бергә татар халкының үсешендәге үзенчәлек аның төрле территорияләрдә таралып урнашуы кебек үзенчәлеген дә китереп чыгарды. Нәтиҗәдә, Татарстан территориясендә бүген татарларның гомуми санының өчтән береннән дә кимрәк өлеше генә яши, бу исә республикадан читтә яшәүче татарларның этномәдәни мәнфәгатьләрен, таләпләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алган дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны таләп итә. Шул сәбәпле Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга теге яки бу дәрәҗәдә барлык татар халкының этномәдәни казанышларын торгызу, саклап калу, үстерү һәм ишәйтү мәсьәләләрен хәл итү дә керә.

17. Татарстанның күпмилләтле халкы барлыкка килүгә һәм аның үсешенә рус халкы вәкилләре зур йогынты ясады. Рус халкының менталитеты һәм рухи кыйбласы республикадагы милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләр характерында сизелерлек чагылыш таба. Рус халкы вәкилләре этномәдәни үсешенең хәзерге бөтен Россия өчен уртак мәсьәләләре Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең аерылгысыз өлеше булып тора.

18. Хәзерге Татарстан территориясендә борынгыдан ук башка халык вәкилләре яши, аларның монда традицион компактлы торак пунктлары күп, димәк, алар үзләренең этномәдәни, этнотел һәм мәгариф өлкәсендәге ихтыяҗларын тиешле институтлар һәм учреждениеләр эшчәнлеге аша дәүләт тәэмин итүенә мохтаҗ.

19. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен формалаштыруга һәм гамәлгә ашыруга миграция процесслары сизелерлек йогынты ясый.

20. Татарстан Республикасында милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең хәзерге торышына, тулаем алганда, тотрыклылык, төрле милләтләр вәкилләренең һәм төрле дин тотучыларның тыныч хезмәттәшлектә булу рухы хас.

21. Шул ук вакытта дини экстремистлык, террорчылык, этнослар үзаңына тискәре йогынты ясаучы традицион булмаган дини идеяләр таралуы белән бәйле яңа куркынычлар һәм хәвефләр килеп чыгуы сәбәпле милләтара (этносара) һәм динара мөнәсәбәтләр өлкәсендә проблемалар туа. Әлеге хәлләр барысы да Татарстан Республикасында милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышына йогынты ясарга мөмкин.

22. Концепцияне гамәлгә ашыру чорында Татарстан Республикасында милләтара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итүдә мөһим нәтиҗәләргә ирешелде. Социологик сораштырулар йомгаклары буенча 2018 елда сораштыруда катнашкан барлык республика халкының 80,4 проценты Татарстанда милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең торышына уңай бәя бирде, 90 проценттан артыгы үзләренә карата милләте, теле һәм диненә кагылышлы билгеләр буенча дискриминация булмавын, ә гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсе 80 проценттан артыграк дип билгеләп үтте.

## III. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең максаты, принциплары, өстенлекле юнәлешләре һәм бурычлары

23. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең максаты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) бөтен Россиядә милләтләр татулыкны ныгыту, сәяси һәм социаль тотрыклылыкны тәэмин итү, демократик институтларны үстерү;

б) Россия Федерациясе күпмилләтле халкының (Россия милләтенең) бердәмлеген, гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту;

в) кешенең һәм гражданның расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәтенә һәм вазыйфасына, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, нинди иҗтимагый берләшмәгә керүенә һәм башка шартларга карамастан, аның хокуклары һәм ирекләре тигезлеген тану һәм яклау;

г) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче барлык халыклар вәкилләренең үсеше һәм тормыш алып баруы өчен сәяси-хокукый, социаль-икътисадый, рухи-әхлакый, мәдәни-көнкүреш һәм башка шартларны тиешле дәрәҗәдә үтәү;

д) Татарстан Республикасының этномәдәни һәм телләр төрлелеген, Россия җәмгыятенең нигезе буларак традицион рухи-әхлакый хәзинәләрне саклап калу, үстерү һәм тиешле дәрәҗәдә саклау;

е) милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайга салу;

ж) Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының яңа шартларга уңышлы социаль һәм мәдәни җайлашуы һәм аларның Россия җәмгыятенә керешеп китүе;

з) каршылыклы хәлләр килеп чыгуны, террорчылык һәм экстремистлык чагылышларын профилактикалау.

24. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең төп принциплары түбәндәгеләр:

а) кешенең һәм гражданның расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәтенә һәм вазыйфасына, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, нинди иҗтимагый берләшмәгә керүенә һәм башка шартларга карамастан, аның хокуклары һәм ирекләре тигезлеге;

б) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның һәм этник берлекләрнең үсеше өчен тигез шартлар тәэмин итү;

в) нинди дә булса шартлар куймыйча, гражданнарның рухи-әхлакый, дини һәм мәдәни-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

г) социаль чыгышына, расасы, милләте, теле һәм диненә кагылышлы билгеләр буенча дискриминациянең теләсә кайсы рәвешләрен профилактикалау;

д) гражданнарның милли горурлыгына хөрмәт белән карау, расачыл, милли һәм дини нәфрәт яисә дошманлык кабызу омтылышларын булдырмау һәм аларга киртә кую;

е) милләтара (этносара) һәм конфессияара каршылыкларны һәм низагларны хокукый нигездә вакытында һәм тыныч юл белән хәл итү;

ж) Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм телләр төрлелегенә, республиканың һәм тулаем Россия җәмгыятенең мөһим стратегик ресурсы булып торган иҗади мөмкинлекләренә дәүләт ярдәме күрсәтү;

з) Россия Федерациясе халыклары вәкилләренең бердәмлек һәм үзара ярдәм кебек тарихи гореф-гадәтләрен буыннан-буынга тапшыра килү;

и) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеге, дәүләт корылышы һәм иҗтимагый тормышны җайга салу мәсьәләләрен хәл итүдә барлык халык вәкилләренең тигез хокуклы катнашуы;

к) аларның тармакара үзенчәлеген исәпкә алып, дәүләт милли сәясәте мәсьәләләрен хәл итүгә комплекслы якын килү алымнарын куллану;

л) расага кагылышлы, милли һәм дини билгеләр буенча сәяси партияләр оешуны булдырмау;

м) Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең ачыклыгы һәм хәбәрдарлыгы.

25. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсендәге бурычлар:

а) гражданнарның тигез хокуклылыгын, аларның конституциячел хокукларын тәэмин итү;

б) бербөтен милли-дәүләт тәңгәллеген (гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеген) формалаштыру;

в) милләтара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайга салуны, экстремистлыкны профилактикалау, милли һәм дини җирлектәге каршылыклар килеп чыгуны кисәтү;

г) Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен социаль-икътисадый шартлар тәэмин итү;

д) Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм рухи үсешенә булышлык итү;

е) белем бирү процессларының барлык этапларында балаларда һәм яшьләрдә гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеге, ватанпәрвәрлек, гражданлык җаваплылыгы, үз Ватаны тарихы белән горурлану хисе формалаштыру, яшь буынны Татарстан Республикасында

яшәүче халык вәкилләренең мәдәниятенә, теленә, традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт рухында тәрбияләү;

ж) Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтләр арасында аралашу теле буларак рус телен саклап калу һәм үстерү;

з) Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү;

и) чит ил гражданнарының Татарстан Республикасында социаль һәм мәдәни шартларга җайлашуы, аларның Россия җәмгыятенә керешеп китүе;

к) Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү;

л) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеген камилләштерү;

м) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү;

н) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда халыкара элемтәләрне үстерү.

26. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләр нигезендә гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту өлкәсендә:

гражданлык тәңгәллеге, ватанпәрвәрлек, гражданлык җаваплылыгы, үз Ватаны тарихы белән горурлану хисе формалаштыру, гражданнарга һәм милли өстенлекләргә, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләренә карата хөрмәт белдерүгә нигезләнгән милләтара аралашу культурасы тәрбияләү;

мәгарифнең күпмәдәниятле моделен үстерү һәм гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту;

белем бирүнең төрле баскычларында мәгариф программаларын, шулай ук Россия Федерациясе халыкларының үзара эшчәнлек алып баруы тарихи тәҗрибәсен, гомумроссия бердәмлеген формалаштыруга йогынты ясаган мөһим вакыйгаларны өйрәнү буенча уку-методика комплексларын камилләштерү;

Татарстан Республикасының этномәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклап калу һәм үстерү максатларында Россия тарихына һәм мәдәниятенә, дөнья мәдәни хәзинәләренә хөрмәт тәрбияләү белән бергә мәгариф оешмаларында уку-укыту системасын камилләштерү;

гомуми белем бирү оешмаларының уку программаларына мәдәни хәзинәләрне һәм халыкларның гореф-гадәтләрен, аларның үзара хезмәттәшлегенең уңай тәҗрибәсен өйрәнү буенча курслар кертү;

балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән җәмәгать башлангычларына булышлык күрсәтү;

республиканың этномәдәни үзенчәлеген исәпкә алып, педагогик кадрлар әзерләү, аларны һөнәри яктан яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү;

б) гражданнарның конституциячел хокукларын тәэмин итү өлкәсендә:

кешенең һәм гражданның расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәтенә һәм вазыйфасына, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, нинди иҗтимагый берләшмәгә керүенә һәм эшкә урнашкан вакытта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгәндә, кадрлар резервын формалаштырганда килеп чыккан башка шартларга карамастан, аның хокуклары һәм ирекләре тигезлеген тәэмин итү;

гражданнарның үзенең нинди милләт вәкиле булуын, шул исәптән Бөтенроссия халык санын алу вакытында да, ирекле рәвештә билгеләве өчен шартларны саклап калу;

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары үз эшчәнлеген тормышка ашырганда кешене милләтенә кагылышлы билгеләр буенча дискриминацияләүне булдырмау өчен чаралар күрү;

в) Россия Федерациясенең күмилләтле халыкның (Россия милләтенең) гражданлык бердәмлеген ныгыту, Татарстан Республикасының этномәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклап калу һәм үстерү өлкәсендә:

ватанпәрвәрлек, халыклар бердәмлеге һәм дуслыгы, милләтара (этносара) татулыкны пропагандалау юлы белән халыкларның рухи, тарихи һәм мәдәни мирасын һәм мөмкинлекләрен саклап калу һәм арттыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның тарихын, мәдәниятен һәм телен, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру белән бәйле дәүләт бәйрәмнәрен һәм истәлекле даталарны билгеләп үтү өчен нигез булып торучы мөһим тарихи вакыйгаларны өйрәнүгә кызыксынуны арттыру;

Ватан тарихын бозып күрсәтү омтылышларын кисәтү;

милләтара (этносара) мөнәсәбәтләр культурасын саклап калу һәм үстерү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның классик һәм заманча әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен, халык сәнгать иҗаты әсәрләрен популярлаштыру һәм тарату, сәнгать күргәзмәләрен, фестивальләрне, конкурсларны, иҗат коллективлары гастрольләрен һәм мәдәният өлкәсендәге башка эшчәнлек төрләрен оештыру һәм аларга ярдәм күрсәтү;

этнография һәм мәдәни-танып-белү туризмы, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) кергән сәламәтләндерү һәм рекреация зоналарын үстерү;

спортның милли төрләренә булышлык күрсәтү;

балалар һәм яшьләрнең тарихи һәм мәдәни мирас объектларында (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр), истәлекле урыннарда, герой-шәһәрләрдә һәм сугышчан дан шәһәрләрендә булуын оештыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның тарихы һәм мәдәнияте буенча белгечләрне һөнәри әзерләү системасын камилләштерү;

мөһим тарихи вакыйгаларны яктыртучы һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның казанышларын пропагандалаучы фәнни тикшеренүләргә, фәнни-популяр мәкаләләргә, әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә, кино һәм телевидениегә, халык сәнгать иҗатына, интернет-ресурсларга дәүләт ярдәме күрсәтү;

милли-мәдәни һәм дини объектлар булдыруга һәм аларны торгызуга, төзекләндерүгә һәм аларны файдалануга булышлык итү;

г) милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны, милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайга салуны тәэмин итү өлкәсендә:

экстремистлыкка һәм террорчылыкка каршы көрәшү өлкәсендә гражданнарга хокукый мәгълүмат бирү;

этномәдәни һәм җәмәгать берләшмәләрен, дини оешмаларны милләтара һәм конфессияара диалогны үстерү, экстремистлыкка, җәмгыятьтә башка милләтләрне һәм диннәрне кабул итә алмау чагылышларына каршы көрәшү буенча эшчәнлеккә җәлеп итү;

җәмгыятьтә һәм массакүләм мәгълүмат, электрон коммуникация чараларында экстремистлык, ксенофобия, милли өстенлек идеяләрен пропагандалауга каршы көрәшү;

сайлау процессында милли һәм дини факторларны файдалануны профилактикалау буенча хокукый һәм мәгълүмати чараларны гамәлгә ашыру;

д) Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен социаль-икътисадый шартларны тәэмин итү өлкәсендә:

муниципаль берәмлекләрнең тигез, комплекслы һәм системалы үсешен тәэмин итүдә этномәдәни факторны исәпкә алу;

халык промыселлары һәм һөнәрләрен үстерүгә булышлык итү;

дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә тармакларда һәм тармаклар арасында кабул ителгән дәүләт һәм муниципаль программаларның туры килүен эшләү, гамәлгә ашыру, тәэмин итү;

Татарстан Республикасының милли-мәдәни иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен Россия Федерациясе төбәкләре, якын һәм ерак чит илләр белән сәүдә-икътисадый һәм мәдәни элемтәләрне үстерү процессына җәлеп итүгә булышлык итүче шартлар булдыру;

е) Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм милләтләр арасында аралашу теле буларак рус телен саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тәэмин итү өлкәсендә:

Россия Федерациясенең дәүләт теле буларак рус телен иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә куллану;

мәгариф, фән һәм мәдәни өлкәләрдә рус теленә булышлык итүнең төрле формалары өчен шартлар булдыру;

күпмәдәниятле мохит шартларында милләтләр арасында аралашу теле буларак рус теленең гамәлдә булуын һәм аның актив үсешен тәэмин итү;

рус телен һәм әдәбиятын популярлаштыру, халыкның язма һәм сөйләм телен белү дәрәҗәсен һәм тел культурасын күтәрү;

ж) Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче халыкларның туган телләрен саклап калу һәм үстерү өлкәсендә:

Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче халыкларның туган телләрен саклап калу һәм үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасы белән таныштыру максатында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен өйрәнү;

Россия дәүләтенең этномәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклап калу һәм үстерүнең нәтиҗәле юлы буларак, мәгариф системасында икетеллелектән һәм күптеллелектән файдалану;

гражданнарның туган телләрен өйрәнүгә хокукын тәэмин итү;

республикада мәгариф һәм милли телләрдә белем һәм тәрбия бирү системасын үстерү өчен хокукый һәм матди шартлар тудыру;

гражданнарның туган телләрен һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләрен өйрәнү өчен тиешле матди һәм оештыру шартлары булдыру;

Россия Федерациясе халыклары телләре буларак туган телдә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем алу һәм Россия Федерациясе халыклары телләре буларак туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру;

гражданнарның ирекле рәвештә аралашу, белем һәм тәрбия алу һәм иҗат итү телен сайлау хокукын бозуны булдырмау;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телендә теле- һәм радио программалар, аудио- һәм видеоматериаллар чыгаруга, интернет-ресурслар булдыруга, басма продукция нәшер итүгә булышлык итү;

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга туган телләрен саклап калу һәм үстерүдә булышлык итү;

з) чит ил гражданнарының Татарстан Республикасында социаль һәм мәдәни шартларга җайлашуы һәм аларның Россия җәмгыятенә керешеп китүе өчен шартларны тәэмин итү өлкәсендә:

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының граждан җәмгыяте институтлары һәм эш бирүчеләр белән берлектә чит ил гражданнарының Татарстан Республикасында яңа шартларга җайлашуы һәм Россия җәмгыятенә керешеп китүе буенча чаралар эшләве, аларны куллануга кертү һәм тормышка ашыру;

мигрантларның һәм аларны кабул иткән җәмгыятьнең мәдәни-көнкүреш өлкәсендә бер-берсенә карата ихтирамлы мөнәсәбәттә булуын тәэмин итүче чаралар системасын камилләштерү;

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының социаль һәм территориаль яктан аерымлануын булдырмау һәм аңа китерүче шартларны бетерү;

чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни шартларга җайлашуында граждан җәмгыяте институтларының ролен арттыру, граждан җәмгыяте институтларының күпфункцияле үзәкләр, шулай ук чит ил гражданнарына

юридик, социаль, мәгариф һәм башка хезмәтләр күрсәтүче оешмалар эшчәнлегендә катнашуына булышлык итү;

миграция процессларын җайга салуны өйрәнү һәм фәнни-экспертлык хезмәте белән тәэмин итү;

чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның ирекле рәвештә Татарстан Республикасына күчеп килүе өчен икътисадый һәм социаль шартлар булдыру;

и) дәүләт идарәсен камилләштерү өлкәсендә:

дәүләт милли сәясәтен тормышка ашырганда, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеген координацияләү системасының нәтиҗәлелеген арттыру;

Россия Федерациясенең күпмилләтле халыкның (Россия милләтенең) гражданлык бердәмлеген ныгыту, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калу максатларында дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуга юнәлтелгән ведомствоара үзара эшчәнлекне, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары белән хезмәттәшлек итү юлы белән үстерү;

экстремистлыкны профилактикалау һәм милләтара (этносара) һәм конфессияара каршылыкларны һәм киеренкелекне алдан кисәтү өлкәсендә дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм вазыйфаи затларының вәкаләтләрен һәм җаваплыгын билгеләү;

граждан җәмгыяте институтларының, шул исәптән милләтара җәмәгать берләшмәләренең, милли-мәдәни мохтариятләрнең, милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә каршылыкларны бетерүгә юнәлтелгән эшчәнлек алып баручы башка оешмаларның Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте мәсьәләләрен хәл итүдә тагын да активрак катнашуы өчен оештыру-хокукый һәм икътисадый шартлар булдыру;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр һәм низаглы хәлләрне алдан кисәтү өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын камилләштерү;

дәүләт милли сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү;

дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруга юнәлтелгән дәүләт һәм муниципаль программаларны нәтиҗәле рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны фәнни яктан һәм экспертлык хезмәте күрсәтү ягыннан тәэмин итүне камилләштерү;

дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру максатларында эшләнгән өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри яктан яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

этномәдәни инфраструктураны: халыклар дуслыгы йортларын, милли мәдәният үзәкләрен, дәүләт милли сәясәте мәсьәләләрен хәл итүгә

юнәлтелгән эшчәнлек алып баручы башка дәүләт һәм муниципаль оешмаларны үстерү;

халыкның барлык этноконфессиональ төркемнәренә үз инициативаларын күрсәтү өчен шартлар тудыру максатларында җирле үзидарә эшчәнлеген оештыруны камилләштерү, шулай ук җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә аларның мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алу;

к) Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруда граждан җәмгыяте институтларының катнашуын тәэмин итү өлкәсендә:

граждан җәмгыяте институтларын, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасын, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары каршындагы иҗтимагый советларны, Татарстан Халыклар ассамблеясен, Бөтендөнья татар конгрессын, Татарларның федераль милли-мәдәни мохтариятен дә кертеп, Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлтелгән идарәчел карарларны эшләүгә, гражданлык үзаңын күтәрүгә, милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә каршылыкларны бетерүгә, чит ил гражданнарының Татарстан Республикасында социаль һәм мәдәни җайлашуын һәм аларның Россия җәмгыятенә керешеп китүен тәэмин итүгә, шулай ук экстремизмны профилактикалауга һәм милли һәм дини җирлектәге низагларны кисәтүгә җәлеп итү;

Татарстан Халыклар ассамблеясенә, Бөтендөнья татар конгрессына, Татарларның федераль милли-мәдәни мохтариятенә, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә каршылыкларны бетерүгә, чит ил гражданнарының Татарстан Республикасында социаль һәм мәдәни җайлашуын һәм аларның Россия җәмгыятенә керешеп китүен тәэмин итүгә, шулай ук экстремизмны профилактикалауга һәм милли һәм дини җирлектәге низагларны кисәтүгә юнәлтелгән эшчәнлекләрендә ярдәм күрсәтү;

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары каршында төзелгән иҗтимагый советларның һәм башка консультатив органнарның, эксперт советларының гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеген арттыру, милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә каршылыкларны бетерү, чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни җайлашуын һәм Россия җәмгыятенә керешеп китүен тәэмин итү эшчәнлегендә катнашуы;

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлегенә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә каралган иҗтимагый күзәтчелек механизмнарын файдалану;

милләтара (этносара) хезмәттәшлек, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның үзенчәлеген, мәдәниятен, телен һәм гореф-гадәтләрен саклап калу һәм яклау, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуы һәм республика тормышына керешеп китүе өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә

ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан эшләнә торган, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлтелгән проектларны финанслау чыганаклары турындагы мәгълүматның һәркемгә ачыклыгын тәэмин итү;

граждан җәмгыяте институтларын, шул исәптән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен балалар һәм яшьләр даирәсендә милләтара (этносара) килешмәүчәнлек яисә дошманлык чагылышларын булдырмауга юнәлтелгән чараларны уздыруга тарту;

дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлтелгән волонтерлык (ирекле ярдәмчеләр) хәрәкәтенә ярдәм күрсәтү;

л) Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны мәгълүмат белән тәэмин итү өлкәсендә:

дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен яктыртучы массакүләм мәгълүмат чараларын, интернет-ресурсларны әлеге Концепциянең максатларын һәм бурычларын үтәүгә җәлеп итү, шулай ук аларны бу өлкәдә проектлар булдыруга кызыксындыру;

дәүләт милли сәясәте максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру өчен реклама һәм башка мәгълүмати продукцияне булдыру һәм тарату;

милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләргә кагылышлы мәсьәләләрне яктыртучы журналистларны әзерләү, һөнәри яктан яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү;

милләтара (этносара), милләтара һәм мәдәниятара хезмәттәшлек мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурслар оештыру һәм уздыру;

Россия Федерациясе субъектлары белән милли телләрдә телевидение һәм радио тапшырулары, аудио- һәм видео материаллар, басма продукция алмашу;

татарлар яшәгән территорияләрдә күрсәтү өчен татар телендә телевидение программалары эшләү;

милләтара (этносара) яисә конфессияара нәфрәт яисә дошманлык кабызуга юнәлтелгән мәкаләләр басылып чыгуны булдырмау өчен җәмәгать контроле чараларыннан файдалану;

м) халыкара элемтәләрне үстерү өлкәсендә:

Россия Федерациясенең чит илләрдә уңай образын, аңа гражданнарның милли мәдәни ихтыяҗларын (этномәдәни ихтыяҗларын) канәгатьләндерүне гарантияләүче демократик дәүләт буларак мөнәсәбәтне формалаштыруга ярдәм итү;

этномәдәни үсеш программаларын гамәлгә ашыру өлкәсендә халыкара, бөтенроссия һәм төбәк милли берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү;

Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә татарлар берләшмәләренең үзләре яши торган илләрдә үз хокукларын тәэмин итү, тарихи Ватаннары белән бәйләнешләрен саклап калу буенча эшчәнлеген берләштерүгә ярдәм итү;

татарларның шактый зур төркемнәре яшәгән чит илләр, Россия Федерациясе субъектлары һәм чит ил диаспоралары белән даими мәдәни һәм икътисадый элемтәләр урнаштыру;

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга Татарстан Республикасындагы милли-мәдәни иҗтимагый берләшмәләр белән элемтәләрен киңәйтү аша милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә ярдәм итү;

неонацизмның теләсә нинди чагылышларына, расизмның хәзерге формаларына, милләтчелек, ксенофобия, русофобия, шулай ук дөнья сәясәтендә каршылыкны көчәйтү һәм җиңелгәннәрнең ничек тә өстенлек алырга теләве максатларында ялган тарих язарга, Икенче бөтендөнья сугышы йомгакларын кабаттан карап тикшерергә, 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында совет халкы яулаган җиңүнең әһәмиятен киметергә тырышуына каршы торуга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру.

## IV. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру инструментлары һәм механизмнары

27. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру инструментлары түбәндәгеләр:

а) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары;

б) федераль, республика һәм муниципалитетлар дәрәҗәсендә эшләнгән стратегик планлаштыру документлары;

в) Россия Федерациясенең «Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы, Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтенең аерым юнәлешләре белән бәйле башка дәүләт программалары;

г) Татарстан Республикасының «2014–2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру»; «2014–2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклап калу, өйрәнү һәм үстерү», «Татар халкының милли тәңгәллеген саклап калу (2014–2021 елларга)» дәүләт программалары, Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең аерым юнәлешләрен гамәлгә ашыру белән бәйле башка дәүләт программалары;

д) муниципаль берәмлекләрнең дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлтелгән программалары;

е) милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр һәм низаглы вазгыятьләрне иртә кисәтү өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмати мониторинг системасы;

ж) «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне һәм дини һәм милли җирлектәге низагларны иртә кисәтү өлкәсендә комплекслы мониторинг системасы» дәүләт мәгълүмати системасы;

з) Татарстан Республикасы дәүләт телләренең һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләренең торышын һәм аларга ярдәм итүне мониторинглау.

28. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасында Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшли һәм раслый.

29. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре нигезендә иҗтимагый берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлектә башкара.

30. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, граждан җәмгыяте институтларының килештерелгән эшчәнлеге, әлеге Концепция нигезендә эшләнгән сәяси, хокукый, оештыру, социаль-икътисадый, мәгълүмати һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру аша тәэмин ителә.

31. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасында милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы мәсьәләләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет тарафыннан карала.

32. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, фәнни һәм башка оешмаларның Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендәге эшчәнлеген координацияләү чараларын күрү Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме тарафыннан тәэмин ителә.

33. Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруның аеруча актуаль мәсьәләләре Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы киңәшмә һәм консультация органнары вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы Куркынычсызлык советы утырышларында каралырга мөмкин.

34. Әлеге Концепция шулай ук халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру турында килешүләр, төбәкара килешүләр төзү, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар кабул итү юлы белән дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

35. Әлеге Концепциянең республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырылуына мәгълүмати ярдәм күрсәтү кызыксынган дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, дәүләт фәнни һәм мәгариф оешмаларының, массакүләм мәгълүмат чараларының һәм этномәдәни юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның мәгълүмати ресурсларын җәлеп итү аша башкарыла.

36. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

а) республикада милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышын, башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте бурычларын гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләргә мөмкинлек бирүче төп характеристикаларны (индикаторларны) эшли һәм раслый;

б) әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруны контрольдә тота, аның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Президентына мәгълүмат бирә.

37. Әлеге Концепциягә төзәтмәләр кертү Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру вакытында килеп чыккан мәсьәләләрне хәл итү зарурлыгын исәпкә алып, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенең торышы һәм перспективалары, шулай ук Россия Федерациясенең 2025 елга кадәрге чорга дәүләт милли сәясәте стратегиясе нигезендә башкарыла.

## V. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре

38. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре түбәндәгеләр:

а) гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсе (процентларда);

б) милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең (процентларда) торышын уңай бәяләүче гражданнарның өлеше;

в) үзләренә карата милләте, теле һәм диненә кагылышлы билгеләр буенча дискриминация булмавын билгеләүче гражданнар өлеше (процентларда);

г) чит ил гражданнарына карата тискәре мөнәсәбәт тоймаучы гражданнар өлеше (процентларда);

д) этносара һәм динара каршылыклар килеп чыгу очраклары саны.

39. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре исемлегенә аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча төгәллек кертелергә мөмкин.

## VI. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

40. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре:

а) гражданлык бердәмлеген, гомумроссия гражданлык һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту, шулай ук Россия Федерациясендә бердәм мәдәни мәйданны формалаштыру;

б) милләтара (этносара) һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә низаглы хәлләрне булдырмау, аларны тыныч юл белән хәл итү;

в) рус телен Россия Федерациясенең дәүләт теле, милләтара аралашу теле буларак саклап калу һәм шуңа ярдәм итү;

г) Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен саклап калу, үстерү

һәм шулай ук өйрәнү һәм шуңа ярдәм күрсәтү өчен шартлар булдыруны тәэмин итү;

д) Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни җайлашуы өчен шартлар тудыру;

е) Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә төбәкара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкара элемтәләрне үстерү;

ж) Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тәэмин итү.

41. Әлеге Концепцияне гамәлгә ашыру милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрдә каршылыкларны бетерүгә, Россия Федерациясе халыкларын төрле яклап үстерүгә, җәмгыятьтә ксенофобия һәм радикальлек очракларын киметүгә, Россиянең күпмилләтле халкының рухи һәм гражданлык бердәмлеген арттыруга этәргеч бирергә тиеш.

---